КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 23 июль г.Казань № 545

Казан шәһәре чикләрендәге Казансу елгасы акваториясендә триатлон буенча спорт ярышларын уздырганда су объектларыннан файдалану турында

Россия Федерациясе Су кодексы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләрнең тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 23 апрель, 256 нчы карары нигезендә, Казан шәһәре чикләрендәге Казансу елгасы акваториясендә триатлон буенча Татарстан Республикасы чемпионатын, Казан шәһәренең акватлон буенча чемпионатын һәм беренчелеген һәм «Казан триатлоны – 2025» республика ярышларын (алга таба – триатлон буенча ярышлар) уздырганда кешеләр тормышы иминлеген тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елның 25 июлендә Казан шәһәре чикләрендәге Казансу елгасы акваториясендә триатлон буенча ярышлар үткәрү чорында Кремль дамбасыннан алып 3 нче транспорт дамбасына кадәрге участокта яр буеннан 600 метр ераклыкта азсыешлы судноларны, шулай ук җилкәнле, ял итү, спорт судноларын (гидроциклларны, байдаркаларны, ишү көймәләрен кертеп) 6 сәгать 00 минуттан алып 15 сәгать 30 минутка кадәр һәм 2025 елның 26 июлендә – 5 сәгать 00 минуттан алып 15 сәгать 00 минутка кадәр куллануны тыюны (алга таба – тыю) билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты белән берлектә, халыкка кертелә торган тыю турында, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша мәгълүмат бирү эшен оештырырга.

3. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә тыюны үтәү максатларында көчләрнең һәм чараларның кизү торуын тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

4. Әлеге тыю триатлон буенча спорт ярышларын әзерләү, үткәрү һәм аларда катнашу өчен җәлеп ителгән судноларга кагылмый дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин